СОВЕТ НОВОАКСУБАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКСУБАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЯҢА АКСУБАЙ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10.08.2026 ел. Яна Аксубай № 24

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Советы 19.10.2015 ел, № 5 «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 28.11.2025 N 425-ФЗ Федераль законы, Аксубай муниципаль районы «Яңа Аксубай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл Советы КАРАРы:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Советы 19.10.2015 ел, № 5 «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (26.11. 2018 N 81, 16.12.2019 е N 116, 03.10.2023 № 68, 13.11.2024 № 92 карарлар редакциясендә):

1.1. 2 статьяның 1 пункты: һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, дача хуҗалыгы, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше алып бару өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан гаражларга һәм машина урыннарына карата 0,1 ставкасын 0,3 кә алмаштырырга.;

1.2. 2 статьяның 2 пункты: фатирларга, бүлмәләргә карата 0,2 ставкасын 0,3 кә алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2027 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Яңа Аксубай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка житкерергә һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru ), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru ) законда билгеләнгән вакытта бастырып чыгарырга .

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам..

Совет рәисе,
Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы А.В.Макаров